УДК 821.512.145

***Ә.Т. Сибгатуллина***

## КАРШЫЛЫКЛЫ ШӘХЕС ЗАҺИР БИГИЕВ
## (Doğu ve Batı Arasında Bir Tatar Mollası: Zahir Bigi'nin Hayatı, Romanları ve Seyahatnamesi. Hazırlayan Ahmet Kanlıdere. İstanbul, Ötüken neşriyatı. 2021. 422 s.)

В Турции вышла новая книга о жизни и творчестве татарского писателя Загира Бигиева (1870–1902) под названием «Татарский мулла между Востоком и Западом: жизнь, романы и саяхатнаме Загира Биги» (Стамбул, 2021). Составителем и автором вводной статьи является известный исследователь истории татарской общественной мысли профессор университета Мармара в Стамбуле Ахмет Канлыдере. В книгу включены два романа З.Бигиева и очерк о путешествии по Туркестану. Эти произведения не только переведены на турецкий язык, но и даны на латинской графике в оригинальном слоге. Заслуживает особого внимания вводная статья, где жизнь и творческий путь З.Бигиева анализируются в свете новых источников и порой с неожиданных ракурсов.

**Ключевые слова:** татарская литература, З. Бигиев, переводы на турецкий язык, джадидизм.

A new book about the life and work of the Tatar writer Zagir Bigiyev (1870–1902) has been published in Turkey under the title «The Tatar Mullah Between East and West: Life, Novels and Sayakhatnam Zagir Bigi» (Istanbul, 2021). The compiler and author of the introductory article is a well-known researcher of the history of Tatar social thought, professor of the Marmara University in Istanbul, Ahmet Kanlıdere. The book includes two novels by Z. Bigiev and an essay on the journey through Turkestan. These works are not only translated into Turkish, but also given in Latin script in the original syllable. The introductory article deserves special attention, where the life and career of Z. Bigiev are analyzed with new sources and sometimes from unexpected angles.

**Key words:** Tatar literature, Z. Bigiev, translations into Turkish, Jadidism.

Бертуган кардәше Муса Бигиев (1874 –1949) даими рәвештә татар, төрек, рус, Европа галимнәренең игътибар үзәгендә торса да, абыйсы Заһир Бигиев (1870–1902) турында соңгы вакытларда яңа хезмәтләр бик язылмады, юбилейлары да сизелми генә узып китте. Бәлки шуңа да быел Төркиядә «Өтүкән» нәшриятында басылып чыккан «*Көнчыгыш белән Көнбатыш арасында бер татар мулласы: Заһир Бигинең тормышы, романнары һәм сәяхәтнамәсе*» исемле китапны зур сөенеч һәм кызыксыну белән каршы алдык. Заһир Бигиевнең ике романын һәм сәяхәтнамәсен үз эченә алган, беренче карашка, татар укучысына әллә ни зур яңалык китермәгән кебек күренүче (татар телендә язучының бу өч әсәрен табып уку авырлык тудырмый, алар мәктәп һәм вуз программаларына да кертелгән) әлеге китапның чынлыкта гаять җитди фәнни хезмәт булуын алдан ук искәртеп куя-

сы килә. Чөнки китапны хәзерләгән кеше – үз галимебез (шушы көннәрдә генә вафат булган) Надир Дәүләтнең шәкерте, Мәрмәрә университеты профессоры Әхмәт Канлыдәрә, бер эшкә алынса, темасын бар яклап тикшереп-өйрәнеп, җентекле анализ ясамыйча, китап бастырмас. Бу фикерне аның башка хезмәтләре белән якыннан таныш булган һәр кеше хуплар. Соңгы елларда татар иҗтимагый фикере хакында аеруча актив эзләнеп, бер-бер артлы китаплар чыгарып торган Әхмәт Канлыдәрәнең, әйтик, Гаяз Исхакый буенча язылган хезмәте, әлегә төрки дөньяда язучыбыз турында әйтелгән иң соңгы сүз булып кабул ителергә лаек [Ahmet Kanlıdere, 2019][1]. 2020 ел башында Европада Д. Росснын инглиз телендә басылган «Татар империясе» исемле китабын, төрек теленә бик тиз арада тәрҗемә иттереп, сыйфатлы китап [Danielle Ross, 2020] рәвешендә шул ук елның август аенда төрек укучыларына тәкъдим итү дә Әхмәт әфәнденең фәнни эшне оста итеп оештыра белүенең матур бер үрнәге булып тора. Истанбулның иң абруйлы һәм төрки-татар дөньясы өчен берсеннән-берсе кыйммәтле әсәрләр бастыру өлкәсендә танылган «Өтүкән» нәшриятында Әхмәт Канлыдәрәнең әле яңа гына тагын бер саллы хезмәте «табадан төште»: «*Идел-Урал һәм Төркестанда фикер хәрәкәтләре: дини ислахчылык һәм җәдитчелек*» исемле бу зур күләмле китап [Ahmet Kanlıdere, 2021] һәр татар тарихчысының өстәлендә үз урынын табачагына шөбһәбез юк.

Татар иҗтимагый фикере тарихында Муса Бигиевнең урынын билгеләү өстендә эзләнүләр алып барган вакытта кардәше Заһирның да тормышы һәм иҗаты белән якыннан кызыксына башлаган Ә.Канлыдәрә 1990 елларда ук аның әдәби әсәрләрен төрек теленә тәрҗемә итү һәм оригинал текстларын төрек-латин әлифбасында бирү эшенә керешә, 2005 елда «Мавәраэннәһердә сәяхәт» әсәрен аерым бастырып чыгара, ул арада әдипнең биографиясенә кагылышлы яңа материаллар табыла, шулай итеп, кулыбыздагы яңа китап 2020 елда хәзерләнеп бетеп, әдипнең тууына 150 ел тулу уңае белән нәшриятка бирелә.

Китапның безнең өчен иң кыйммәтле бүлеге, әлбәттә, кереш мәкалә: «Заһир Биги (1870–1902): каршылыклар иясе» исеме белән бирелгән язмасында Ә. Канлыдәрә иң әүвәл язучы хакындагы историографияне барлый, аның турында үзе исән вакытта ук һәм мәрхүм булганнан соң басылган язмаларның башында И. Гаспралы, Ф. Әмирханнар торуын әйтә һәм «Тәрҗеман», «Әлислах» газеталарыннан өзекләр китерә, Абдулла Баттал-Таймас, Зәки Вәлиди Тоган, Наилә Бинарк кебек Төркиядә яшәгән галимнәребезнең язмаларын куллана. Совет чоры татар әдәбияты белгечләренең З. Бигиев иҗатын идеологик кысаларга көчләп кертергә тырышуларын, күбрәк ике романын алгы планга куеп, сәяхәтнамәсен күрмәмешкә салышуларын әйтә, күрсәләр дә, рус-совет сәясәтенә яраклаштырып анализлануын,

[1] Бу хакта кара: [Сибгатуллина, б. 175–178].

текстын бастырганда да, кайбер «уңайсыз» урыннарын төшереп калдыруларын ассызыклый, бары тик 1991 елда Рәис Даутов хәзерләгән китапта гына әсәрнең тулы хәлдә бирелүен искәртә. Явуз Акпынар, Мостафа Токер, Аллен Франк кебек төрек һәм Европа галимнәренең дә З. Бигиев турында язганнарын Ә. Канлыдәрә җентекләп анализлый.

Әдипнең кыска гына гомер юлында ак таплар шактый, әйтик, исемнәре билгеле булып та, җисемнәре табылмаган «Мөртәт» һәм «Катилә» исемле ике романы, 1902 елда фаҗигалы үлеменең сәбәпләре шундыйлардан. Кереш мәкаләсендә Ә. Канлыдәрәнең дә бу билгесез калган урыннарга аерым игътибар итүен, сүз уңаеннан булса да, үз фаразларын бирүен күрергә була. Мәсәлән, бертуган Бигиевләрнең ерак бабалары нугайларның Алтыул ыруыннан булып, Русиянең көньягында урнашкан һәм мишәрләр буларак танылган группага керүе әйтелә, этиләре мулла Ярулла Пенза губернасы Чембар өязендә туып-үсеп, сәүдә белән шөгыльләнү максатында Ростов-Донга күченгәч, мөселман мәхәлләсендә ахун һәм имам вазифаларын башкара, ләкин эчкечелек чиренә бирелеп, бик яшьләй вафат була. Ярулланың егерме биш баласы булуы турындагы хәбәр (Рәис Даутов бастырган китапта да ул бар) Муса Бигиевнең 1908 елда абыйсы Заһир хакында язган мәкаләсендә теркәлә, ләкин моның басмадагы хатамы икәнлеген, яки дөреслеккә туры килү-килмәвен әйтү кыен булганга, Ә. Канлыдәрә, үзе тапкан берничә фактны өстәп, бу сорауны ачык калдыра. Заһир Бигиевнең Ростов-Донда түгел, Чембар өязендә туганлыгы турындагы фикерне дә искәртеп уза.

Кереш мәкаләнең татар әдәбияты тарихына китергән иң зур яңалыгы – моңа кадәр киң кулланышка кереп китмәгән яңа чыганакларга, аеруча З. Бигиевнең атаклы христиан миссионеры һәм тюрколог Евфимий Малов (1835–1918) белән шактый озак вакыт хат язышуына таянып, аның тормыш юлына һәм иҗатына башка күзлектән карау. Шуның нәтиҗәсендә, Заһир Бигиев шәхесенең, безнең мәктәп һәм югары уку йортлары өчен төзелгән дәреслекләрдән аермалы буларак, авторның үз сүзләре белән әйткәндә, «совет белгечләре тасвирыннан шактый аерылып торган портреты» (42 б.) тәкъдим ителә. Е. Малов белән язышуы яшь әдипнең татар һәм рус иҗтимагый тормышына, ислам һәм христиан диннәренә карата булган каршылыклы фикерләрен аңларга ярдәм итә. Рус гимназиясендә белем алган, француз романнары укып үскән Заһир әфәнденең, Казанга килеп, Күл буе мәдрәсәсендә дин гыйлемнәрен укуы, шул ук чорда дөньяви рухлы әсәрләр язуы, аннан соң кире Ростов-Донга кайтып, имам булып эшләве, «ислам дийары» Урта Азия якларына сәяхәт ясап, андагы хәлләрне үз күзе белән күреп кайтуы, якын иптәшенең христиан диненә күчүе вакыйгасы белән бәйле кичерешләре – аның чыннан да Көнбатыш белән Көнчыгыш фикере, ислам һәм гайре ислам мәдәниятләре арасында рухи эзләнүләрен, хәтта бәргәләнүләренраслый торган факторлар. Әхмәт әфәнде язучының яшьли үлеме белән бәй-

ле фаразларга да туктала, үз-үзенә кул салганмы, әллә инде җинаять корбаны булганмы дигән сорауларга турыдан-туры җавап бирмәсә дә, З. Бигиевнең күңел төшенкелегенә бирелүенең, хәмергә ияләшүенең психологик сәбәпләре шактый тирәндә ятуын ачыклый, һәм хатыны тарафыннан үтерелгән булуы мөмкинлеген әйтә.

Ә. Канлыдәрә фикеренчә, иҗатына рус һәм француз әдәбиятының тәэсире никадәр генә үтемле булмасын, З. Бигиевнең интеллектуаль яктан формалашуына иң көчле йогынтыны Русия мөселманнары арасында җәелгән җәдитчелек идеологиясе ясаган. Шунлыктан ул, совет галимнәреннән аермалы буларак, аның тормышын һәм иҗатын җәдитчелек хәрәкәте җирлегендә тикшерергә омтыла. Бүгенге көндә, Татарстанда җәдитчелек-кадимчелек хәрәкәтләре хакында яңа карашлар формалашкан бер чорда, Ә. Канлыдәрәнең бу өлкәдәге фикерләре белән якыннан танышу тарихчыларга да файдалы булыр дип ышанасы килә.

Төрек галиме, «Зур гөнаһлар» романындагы Мәмәт образы аша һәм сәяхәтнамәдәге тарихи шәхес Арминий Вамбери (1832–1913) белән бәйле урыннарда З. Бигиевнең турыдан-туры госманлы-төрек идарәсенә карата тискәре һәм тәнкыйди караш белдерүенә махсус туктала. Моның, нигездә, ул вакытта татарлар арасында таралган Төркиягә һиҗрәт итү шаукымы белән бәйле булуын фаразлаган мәкалә авторы, З. Бигиевнең Е. Маловка язган бер хатында да бу теманы күтәрүен һәм Ростов-Дон шәһәрендә төрекләр ачкан мәчеттә Русиядә яшәгән мөселманнарны солтан Габделхәмид исәнлегенә дога кылырга чакыруларына ачуы килүе кебек моментларны күрсәтә, Русиядәге мөселманнарның рус падишаһына тугры булырга тиешлеге фикерен яклавын, Е. Маловка язган хатларында император Александр III гә мактау яудыруын әйтә. Шул ук вакытта, рус хакимиятенең Төркестанга үтеп керү сәясәтенә әдипнең каршы булуын да белдереп, аның никадәр каршылыклы фикерләр эчендә тормыш итүен тагын бер кат ассызыклый.

Әхмәт әфәнде, З. Бигиев әсәрләренең теле мәсьәләсенә тукталып, татар теле тарихы белән шөгыльләнүчеләр өчен дә кызыклы бер теманы күтәрә: «Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә» һәм «Зур гөнаһлар» романнарының теле XIX йөз Казан татар теле булса, сәяхәтнамәсендә исә язучы нигәдер кисәк кенә госманлы төрекчәсенә якын тел куллана. Моның сәбәбен галим, я абыйсы вафат булганнан соң әсәрне бастырып чыгарган энесе Муса Яруллаһ тарафыннан үзгәртелгән, яки әдип үзе И. Гаспралы алга сөргән уртак төрки тел идеалы йогынтысында шулай язгандыр дип фараз кыла.

Текстлары югалган «Мөртәт» һәм «Катилә» романнары хакында Ә.Канлыдәрә кистереп кенә берни әйтмәсә дә, кереш мәкаләдә уйландырырлык фикерләр юк түгел: дини термин булган «мөртәт»[1] сүзен

[1] Гарәп телендәге «иртида» сүзеннән, «диннән чыккан кеше».

З. Бигиев мәдрәсәдән сабакташы булган һәм соңыннан миссионерлар тырышлыгы белән христиан диненә күчкән Сәхибгәрәй Әхмәров өчен кулланган булырга мөмкин, чөнки динен алыштырган иптәше белән аның арасында фикер алышу һәм бәхәсләшү шактый дәвам иткәне күренә, Е. Малов та көндәлегендә бу турыда яза. Ягъни романның төп герое автор танып-белгән реаль шәхес булып, сюжеты да үз мохитеннән алынган булырга бик мөмкин. Югалган икенче роман белән бәйле рәвештә, төрек галиме түбәндәге истәлеген китерә: совет чоры тарихчысы Р. Нәфыйков 1963 елда «Совет әдәбияты» журналында бастырган бер мәкаләсендә Ленинград Үзәк китапханәсендә «Катилә» романының кулъязмасын табуын хәбәр итә, 1999 елда Казанда Рәфыйк абый белән очрашканда, Әхмәт әфәнде бу әсәр турында аннан сорый, ләкин җавап ала алмый, икенче көнне М. Госманов белән бу хакта сөйләшкәндә, Миркасыйм абый әлеге кулъязманың рус цензурасына бирелгән «Зур гөнаһлар» романының бер нөсхәсе булуын әйтә (32–33 б.), ягъни шул рәвештә әлеге романның чынлыкта язылу-язылмавы да шик астына алына. Кереш мәкаләдәге тагын бер кечкенә деталь кызыклы тоела: Муса Бигиев, үз хезмәтләрен нәшер итүдә шактый актив булса да, вафат булган абыйсының әсәрләрен тиз арада бастырып чыгарырга нигәдер ашыкмый, моңа замандашлары да игътибар итә һәм (бәлки алар басымы белән) 1908 елда «Мавәраэннәһердә сәяхәт» дөнья күрә.

Кыскасы, Әхмәт Канлыдәрәнең кереш мәкаләсе – фактларга бай, эчтәлекле, кызыклы һәм уйланырга урын калдыра торган язма, Заһир Бигиев турында моннан соң ни дә булса язарга теләүче кеше мотлака бу мәкаләне укымыйча яңа бер сүз әйтә алмас, дигән фикер тудыра. Әгәр татар теленә тәрҗемә ителсә, әдәбиятыбыз тарихы белән кызыксынучылар өчен файдалы бер чыганак булачагы шиксез. Китапның төп өлешендә исә башта өч әсәрнең дә төрекчәгә тәрҗемәсе, аннан соң аларның гарәп графикасында басылган оригиналларының төрек-латин әлифбасына күчермәсе урнаштырылган. Гарәп графикасында басылган «Мавәраэннәһердә сәяхәт. Транскоксаниягә сәфәр» китабына (Казан: «Китап» нәшрияты, 1908) кереш рәвешендә язылган М. Бигиевнең «Мөхәммәд Заһир әфәнде Бигиев» исемле мәкаләсе һәм Г. Тукайның әдипкә багышлаган мәрсиясе дә латин хәрефләренә күчерелеп бирелгән. Төркиядә татар телен һәм әдәбиятын өйрәнергә теләүче кешеләргә бер дигән материал булырдай бу текстлар русчадан алынган сүзләргә аңлатмалар һәм искәрмәләр белән тәэмин ителгән, төрек язма телендә кулланылмаган *ә, ң* кебек хәрефләрнең махсус ишарәтләр белән бирелүен дә әйтергә кирәк.

Милли мирасыбызны өйрәнүдә әһәмияте зур булган бу төр гыйльми хезмәтләр даими чыга торсын, укучылары да мул булсын дигән теләктә калабыз.

**Әдәбият**

*Ahmet Kanlıdere.* İdil-Ural ve Türkistan’da Fikir Hareketleri. Dini İslahçılık ve Ceditçilik. İstanbul, Ötüken, 2021. 480 s.

*Ahmet Kanlıdere.* Sosyalizmden Türkçülüğe Kazanlı Ayaz İshaki (1878–1954). İstanbul, Ötüken, 2019.

*Danielle Ross*. Tatar İmparatorluğu. Kazan Tatarları ve Çarlık Rusyası'nın Oluşumu. Türkçesi: Dr. Kadri Mustafa Orağlı. İstanbul, Ötüken yay. 2020.

*Сибгатуллина Ә.* Исхакыйның иҗтимагый-сәяси фикер дөньясы хакында яңа хезмәт // Фәнни Татарстан. 2019. № 2. Б. 175–178.

***Сибгатуллина Әлфинә Таһир кызы**,*
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Росссия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*